ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2019 п.г.т.Алексеевское № 55

**“Инфраструктур үсеш бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раславы турында”гы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 28 декабрь, 2018 ел, 482 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Күп фатирлы өйдә биналарны үзгәртеп төзү һәм (яки) яңадан планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр (27 декабрь, 2018 ел, 558-ФЗ санлы Федераль закон) кертү уңаеннан

**карар бирәм:**

1. “Инфраструктур үсеш бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раславы турында”гы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 28 декабрь, 2018 ел, 482 нче карарына 3 нче кушымтаның 1.5 нче пункты 4 абзацында “торак бинаның” сүзләрен “күп фатирлы өйләрдәге биналар” дигән сүзләргә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Алексеевск муниципаль районының мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне инфраструктур үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**